# КАРАР

**09 декабрь, 2024 ел** **№1**

**Кукмара муниципаль районы Нырья авыл җирлеге Балды-Кня авылында гражданнарның үзара салым чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2024 елның 09 декабрендә 2 этапта түбәндәге мәсьәлә буенча узган гражданнар җыеннары нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенының беркетмәсе төзелде:
«Сез 2025 елда Кукмара муниципаль районының Нырья авыл җирлеге Балды-Кня авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидларыннан; көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлардан (курсантлардан); 18 яшькә кадәрге бала тәрбияләүче ялгыз аналардан; 18 яшькә кадәрге бала тәрбияләүче ялгыз аталардан, 80 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, 1000 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Балды-Кня авылының Гагарин урамы юлын ремонтлау, карап тоту, вак таш җәю (проект-смета документларын эшләү, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, вак таш сатып алу, ташу, салу, килешү буенча эш өчен түләү);

- су белән тәэмин итү системаларын, су суырту манараларын, скважиналарны һәм башка инженерлык челтәрләрен ремонтлау, карап тоту, төзекләндерү (проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру);

- урам яктырту җайланмасы (урам яктырткычлары сатып алу һәм урнаштыру, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, килешү буенча эш өчен түләү)?

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыенының йомгаклау беркетмәсе нигезендә:
Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 108 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны – 59 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча, гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«РИЗА» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы 59 кеше тавыш бирде;

«КАРШЫ» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы 0 кеше тавыш бирде;

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Нырья авыл җирлегенең Балды-Кня авылында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. Түбәндәге мәсьәлә буенча карарны: «Сез 2025 елда Кукмара муниципаль районының Нырья авыл җирлеге Балды-Кня авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидларыннан; көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлардан (курсантлардан); 18 яшькә кадәрге бала тәрбияләүче ялгыз аналардан; 18 яшькә кадәрге бала тәрбияләүче ялгыз аталардан, 80 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә срокלы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, 1200 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Балды-Кенә авылының Гагарин урамында юлларны рәтләү, ремонтлау һәм вак таш җәеп төзекләндерү, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, вак таш сатып алу, ташу, салу, сууткәргеч торбалар урнаштыру, эш өчен шартнамә буенча түләү, юлларны төзү, карап тоту һәм төзекләндерү буенча башка эш төрләре);

- су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су суырту манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, ташуны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (Балды-Кня авылында су белән тәэмин итү челтәрләрен, су саклау зоналарын һәм су суырту манараларын карап тоту, ремонтлау һәм төзекләндерү, материаллар сатып алу, проект-смета документлары, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, су белән тәэмин итүне, су саклау зоналарын һәм су суырту манараларын карап тоту буенча башка эш төрләре);

- коеларны ясау, ремонтлау һәм аларга якын территорияне төзекләндерү (коеларны ремонтлау, карап тоту, төзекләндерү, проект-смета документлары һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, материал сатып алу, эш өчен шартнамә буенча түләү, коеларны төзекләндерү һәм карап тоту буенча башка эш төрләре);

- торак пункт территориясен төзекләндерү (халыкның күпләп ял итү урыннарын (парклар, скверлар, спорт һәм уен мәйданчыклары, халыкның башка күпләп ял итү урыннарын, авыл клубы, аның янәшәсен карап тоту, төзекләндерү, ремонтлау), проект-смета документлары һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, эш өчен шартнамә буенча түләү, Гырон Быдтон паркы территориясен төзекләндерү буенча башка эш төрләре);

- тышкы урам яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм аларга бирелгән башка подстанцияләрне һәм мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (урам яктыртуны карап тоту, яктырткычлар һәм комплектлау материаллары сатып алу һәм урнаштыру, урамнарны яктыртуны карап тоту буенча башка эш төрләре, проект-смета документлары һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру)

«РИЗА» «КАРШЫ»

кабул ителгән дип исәпләргә.

3. Гражданнар җыенның нәтиҗәсен мәгълүмат стендларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Нырья авыл җирлеге башлыгы В.И. Павлов